СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2021 Әгерҗе шәһәре № 13-3

Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының генераль планнарны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, җирле нормативларны раслау, территорияне планлаштыру буенча генераль планнар нигезендә әзерләнгән документларны раслау, эшләү һәм әзерләү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының генераль планнарны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, җирле нормативларны раслау, территорияне планлаштыру буенча генераль планнар нигезендә әзерләнгән документларны раслау, эшләү һәм әзерләү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлекләре советларына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә.

3. Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының генераль планнарны, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, җирле нормативларны раслау, территорияне планлаштыру буенча генераль планнар нигезендә әзерләнгән документларны раслау, эшләү һәм әзерләү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны

Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына тапшыру турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә.

4. Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына тапшыру турындагы килешүләр рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://agryz.tatarstan.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе А.Р. Вәлиев